| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«КУАКБАШСКОЕ СЕЛЬСКОЕ<br>ПОСЕЛЕНИЕ» ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>«ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»<br>МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ<br>«КУАКБАШ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2025 елның 18 декабре КУАКБАШ авылы №15

«Куакбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2016 елның 03 октябрендәге20 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Куакбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2025 елның 3 октябрендәге 66-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Куакбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. «Куакбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2016 елның 3 октябрендәге 20 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Куакбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2025 елның 17 октябрендәге 6 номерлы «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Куакбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» карарын гамәлдән чыгарырга.

2. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Куакбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2016 елның 3 октябрендәге 20 номерлы карары белән расланган «Куакбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә (30.05.2017 №10, 17.11.2017 №24, 29.01.2018 №3, 19.09.2018 №21, 14.12.2018 №31, 22.01.2019 №3, 20.03.2019 №8, 02.10.2019 №25, 12.02.2020 №3, 17.06.2020 №20, 13.08.2020 №22, 12.11.2020 №6, 26.03.2021 №5, 10.08.2021 №23, 28.04.2023 №19, 01.08.2023 №28, 19.10.2023 №39, 18.12.2023 №47, 25.04.2024 №9, 04.10.2024 №26, 18.12.2024 №33 редакциядә), түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2.6.1 һәм 2.6.2 пунктларны түбәндәге редакциядә бирергә:

«2.6.1 һөнәри белем дәрәҗәсенә: югары белем яки урта һөнәри белем булу - югары, төпһәм алып баручы төркем вазыйфалары өчен, шулай ук өлкән һәм кече төркем вазыйфалары өчен;

2.6.2 муниципаль хезмәт стажына яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына:

муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары буенча-кимендә бер ел муниципаль хезмәт стажы яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча кимендә ике ел эш стажы;

муниципаль хезмәтнең төп вазыйфалары буенча - муниципаль хезмәт стажы яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча кимендә бер ел эш стажы.

Алып баручы, өлкән һәм кече төркем муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен муниципаль хезмәт стажына яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына квалификация таләпләре билгеләнми.

Муниципаль хезмәт стажын билгеләгәндә шулай ук дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларында һәм аларга тиңләштерелгән хәрби хезмәт вазыйфаларында һәм федераль дәүләт хезмәте вазыйфаларында эш стажы исәпкә алына.».

3. Әлеге карарны түбәндәге адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә: Татарстан Республикасы, Лениногорск районы , Куакбаш авылы, К. Маркс урамы 15 йорт җирле үзидарә бинасында, Сходнево-Чертанлы авылы Ирек урамы 5Б йорт авыл клубы бинасында, Чуте авылында Тынычлык урамындагы 8А йорт авыл клубында, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (https://leninogorsk.tatarstan.ru/) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам

Лениногорск муниипаль районы
«Куакбаш авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы,
Совет рәисе Р.Р.Әхмәтҗанова